# Сәнәигы нәфисә. Искусствоведение Татарстана: альманах. Выпуск 1. Теория, история, современная художественная практика, арт-рынок

*Басманың концепциясе һәм перспективасы хакында редактор сүзе*

«Сәнәигы нәфисә / Икусствоведение Татарстана: альманах» басмасын эшләүгә алынуымның сәбәбе – Казан сәнгать белгечләренең, рәссамнарның һәм сәнгать сөючеләрнең күптәнге хыялын тормышка ашыру ниятеннән булды.

XX гасыр башында ук инде татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре Габдулла Тукай белән Галимҗан Ибраһимов сәнгать турында «Сәнәигы нәфисә» (нәфис сәнгать) дигән журнал чыгарырга хыялланганнар. Шушы рухтагы журнал чыгару омтылышын, беренче булып, «Туган» мәдәни фонды (президенты С. Хәбибрахманова) ясый һәм 1993–1995 елларда «Татарстан» журналына кушымта рәвешендә аның берничә санын чыгаруга да ирешә.

Әлеге «Альманах» исә сәнгать белеме өлкәсендә, башка басмаларның кушымчасы гына булмыйча, махсус җыентык буларак төзелде. Аның сәнгати-публицистик, әдәби, иҗтимагый-сәяси журналлардан аермасы шунда, бу басмада сынлы сәнгать һәм декоратив-гамәли сәнгать буенча фәнни язмалар урнаштыру күздә тотылмады. Анда, беренче чиратта, ватан һәм дөнья сәнгате киңлегендә Татарстан Республикасының заманча сәнгати тормышындагы мөһим аспектларны чагылдыру бурычы куелды.

Безнең бурыч – сәнгать белеме фәне горизонтларын киңәйтү – фәннәрара тикшеренүләргә төрлечә карашларны, аның методологиясен, киләчәген күрсәтү, инде танылып өлгергән һәм яшь талантлы сәнгать белгечләренең яңа хезмәтләре белән таныштыру. Анда хәзерге этапта музейлар һәм галереяларда оештырылган күпкырлы күргәзмәчелек эшчәнлеге беренче тапкыр зур масштабта яктыртыла.

Сәнгать белгечләренең һәм әйдәүче рәссамнарның сәнгати киңлектә киң яклау тапкан концептуаль идеяләре һәм кураторлык проектлары фәнни яңгыраш алачак һәм алар гаять мавыктыргыч образлы һәм пластик контекстлар өстендә эшләүгә юл ачачак. Мәгълүм булганча, алар бүген бик актуаль һәм заманча фәлсәфи эзләнүләр рухын җанландырып, сәнгати танып белү процессының чикләрен юкка чыгаралар, һәм рәссамнарга (А. Ильясова, И. Хәсәнов, С. Гыйләҗетдинов һ.б.га) үзләрендәге киңкырлы авторлык сәләтен эшкә җигәргә мөмкинлек тудырачак. Басмада рәссамнарның гына түгел, сәнгать белгечләренең дә иҗади портретларына зур урын бирелгән. Моның максаты – рәссамның, сәнгать белеме өлкәсендәге галимнең иҗади шәхесен, аның иҗтимагый һәм социаль статусын күтәрү.

Бүген сәнгать өлкәсендә тикшеренүләр алып баручылар белән беррәттән, гаять киң танылу яулаган осталар, аз өйрәнелгән авторлар, халык сәнгате турында әлегә кадәр билгесез кала килгән фактларга һәм сәнгати һөнәрчелек, кәсепчелекне үстерү хакындагы проблемаларга да басмада киң урын бирелә.

Игътибар үзәгендә – профессиональ рәссамнар, сәнгать белгечләре, арт-базар белгечләре әзерләүнең актуаль проблемалары. Илдәге күренекле фәнни тикшеренү учреждениеләренең үзара элемтәсенә, Россиянең төрле шәһәрләрендәге һәм дөньядагы тар профильле белгечләрне, арт-тәнкыйтьчеләрне, коллекционерларны, галереячыларны, наширләрне басма хезмәтләр әзерләүгә тартуның перспективасы зур. Бу уңайдан «Галеев-галерея» (Мәскәү) тәҗрибәсе игътибарга лаек, ул безнең регион рәссамнары күргәзмәләрен, алар турындагы монографияләрне бастырып чыгару эшен башлап җибәрде. Аның проектларында коллекционерның шәхси зәвыгы илдәге аз билгеле сәнгатьне өйрәнүнең актуальлеге белән тәңгәлләшә. Бу проектны тормышка ашыруның бүгенге этабында ук инде Мәскәү, Идел буе регионы һәм төрки дөньяның танылган сәнгать белгечләрен (П. Гамзатова, Н. Розенберг, Р. Ергалиева) хезмәттәшлеккә тарту омтылышы ясала.

Соңгы елларда ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИында оештырылган «Төрки халыкларның сәнгати мәдәнияте чыганаклары һәм эволюциясе» (2008), «Төрки дөньяда киез сәнгате: тарихы һәм бүгенгесе» (2009), «Бакый Урманче иҗаты һәм милли сәнгатьнең актуаль проблемалары» (2012), «Россия һәм БДБ илләрендә сәнгать белеме үсешенең актуаль мәсьәләләре» (П.М. Дульскийның тууына 135 ел тулуга багышлана) (2014) дигән халыкара конференцияләр сәнгать белгечләре һәм рәссамнар арасындагы үзара аралашуларны җанландырып җибәрүгә зур йогынты ясады. Шулай ук ТР Сынлы сәнгать дәүләт музее инициативасы белән үткәрелгән «Казанские искусствоведческие чтения» дигән чара да игътибарга лаек.

Беренче чыгарылышның максаты – соңгы елларда (2008 дән башлап) Республика тормышындагы сәнгатьнең төрле аспектларына йомгак ясау, сәнгать өлкәсендә фәнни тикшеренүләр методологиясен яңартуның актуаль бурычларын, үзенчәлекле концепцияләрен, креатив проектларын, перспективасын калку итеп күрсәтү һәм академик фәннәр белән сәнгати эшчәнлекнең нәтиҗәле үсешенә ирешү.

Басманың «Мирас» бүлеге региондагы сәнгать дөньясының аз өйрәнелгән сәхифәләрен ача: гарәп каллиграфиясен фәнни өйрәнү аспектларын, профессиональ рәссамнар (татарлардан беренче скульптор М. Бакиев, рәсем сәнгате остасы Н. Фешин) иҗатын яктырта. Арт-күзәтүгә, репортажларга һәм рәссам, сәнгать белгечләренең әдәби иҗатына зур урын бирелә.

Яшь белгечләр әзерләү проблемасы үзенең актуальлеген

һичкайчан югалтмый, шуңа күрә басмада сәнгать белеме бирүгә багышланган язмаларга, Н. Фешин исем. Казан сәнгать мәктәбе (2015 елда 120 еллыгы билгеләп үтелде) рәссам-укытучысы Н. Фешин турындагы очеркларга зур урын бирелә.

Бүген Республикада Татарстандагы «Россия Рәссамнары берлеге», Татарстан Республикасының Рәссамнар берлеге, Татарстан рәссамнары тәшкиләте, Россия Рәссамнар берлегенең Татарстан һәм Яр Чаллы рәссамнары профессиональ бүлеге эшли. Безнең фикеребезчә, бу оешмалар барысы да бердәм иҗади пространствоның бер өлешен тәшкил итә һәм заманыбызның сәнгати процессы аспектларын төрле яклап чагылдыра, шул ук вакытта зур фәнни кызыксыну тудыра.

1935–1936 елларда Татарстанда мөстәкыйль эшли башлаган, рәссамнарны һәм сәнгать белгечләрен берләштергән (ул вакытта әле СССРның да, РСФСРның да Рәссамнар берлеге формалашмаган була) бу оешма бай традицияләргә ия. 2016 елның декабрендә без үзебезнең иҗади берлегебезнең 80 еллыгын билгеләп үттек.

Альманахның бу чыгарылышы шушы мөһим вакыйгаларга багышлана.

***Солтанова Рауза Рифкать кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире*